# Җилкәңдә булса башың!

Рамил Чурагулов сүзләре

Фәнир Галимов көе




1
Сөйләреңне сөйләрсең син
Сөяреңне сөярсең.
"Каф таулары биек", димә,
Хәтта күккә менәрсең.

*Кушымта:*
Нәфсеңне тый, үлчәп эш ит,
Хәрәм булмасын ашың.
Оҗмах булыр яшәешең
Җилкәңдә булса башың!

2
"Мин болай булырмын", димә,
"Мин болай булмам", димә.
Ходай кемгә таудай бәхет,
Кемгә актыгын бирә.

3
Сүзләр бирсәң, сүзеңдә тор,
Егет сүзе бер була.
Максат куеп ирешкәннәр
Һәрчак бәхетле була.